ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 147 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турындагы хәбәрнамә текстын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составына билгеләп кую өчен хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалар кандидатуралары турындагы тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм 2019 елның 25 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бәяләмә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Л.Н. Мавринага йөкләргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 20 сентябре
№ 47-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2019 елның 20 сентябрендәге
47-VIДС карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы**
**ХӘБӘРНАМӘСЕ**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы Воронова Ольга Михайловнаның вәкаләтләре алдан туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә бер вакантлы урынга Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасын билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул ителә.

Кандидатуралар буенча тәкъдимнәр һәм закон таләпләре нигезендә тутырылган документлар әлеге хәбәрнамә рәсми басылып чыккан көннән өч көн дәвамында 9 дан 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 нче йорт, 711 нче кабинет (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты).

---